ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.05.2020 ел Баулы шәһәре №98

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында»гы 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2020 елның 24 апрелендәге «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 17 номерлы канунын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында" 2018 елның 11 декабрендәге 454 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 февралендәге 21 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 пунктта «2.16.,» санынннан соң. «2.17.," санын өстәргә;

Карарга «Баулы муниципаль районы территориясендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге» кушымтасында “Татарстан Республикасы Кодексының 2.16 статьясы. Балигъ булмаганнарга тәмәкесез никотинлы продукция сатуны, никотин китерүнең электрон системаларын сатуны, шулай ук балигъ булмаганнарны

тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итүне тыю таләбен үтәмәү» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| ТР КоАП, 2.17. статья<br>Яңа коронавируслы - инфекция (COVID-19) таралу нәтиҗәләрен булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктының әйдәп баручы белгечләре;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге начальнигы;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы һәм баш белгече;<br>- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау бүлегенең әйдәп баручы белгече. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров